ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» сентября 2026 ел № 235

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм файдалануга рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 29.07.2021 елның 241 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 333.33 һәм 333.35 статьяларына үзгәрешләр кертү турында" 2026 елның 25 маендагы 142-ФЗ номерлы федераль законы, "Реклама турында "Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы федераль законы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм файдалануга рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 29.07.2021 елның 241 номерлы карарына (алга таба - Карар), түбәндәге үзгәрешләр кертерг:

1.1. Карар преамбуласыннан "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 елның 880 номерлы карары, " сүзләрне төшереп калдырырга.

2. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең карар белән расланган административ регламентында (алга таба-Регламент):

2.1. 1 бүлекнең 1.3.2 пунктының 3 пунктчасында "төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә" дигән сүзләр "төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә" дигән сүзләр белән алыштырырга;

2.2. 2.8 бүлегенең 2.8.2 пунктының 6 пунктчасында "5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә" дигән сүзләр "реклама конструкциясен урнаштыру һәм

эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йортта йорт хуҗаларының гомуми мөлкәтен 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә" дигән сүзләр белән алыштырырга;

2.3. 2.9 бүлегенең 2.9.1 пунктының 2 абзацында "5000" саннары "10000" саннары белән алыштырырга;

2.4. 2.10 һәм 2.11 бүлекләрен төшереп калдырырга.

2.5. 3.5 бүлегенең 3.5.1 пунктының 2 абзацында, 3.6 бүлегенең 3.6.1 пунктының 2 абзацында "Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге" сүзләрен "Төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге" сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**